**9 нчы сыйныф**
**Татар теле**

Тема: **ь һәм ъ хәрефләренең дөрес язылышы. Сүзләрне кушып, сызыкча аша һәм аерым язу.**

# Тест биремнәрен үтәгез

1. Орфография нәрсәне өйрәнә?

а) әдәби телдә дөрес язу нормалары һәм кагыйдәләре;

б) әдәби телдә дөрес сөйләү нормалары һәм кагыйдәләре;

в) авазларның язуда белдерелүен.

2. Татар телендә ничә сузык аваз хәрефе бар?

а) 8 б) 9 в) 10

3. Һ хәрефе языла торган рәтне билгелә.

а) .алык, .өкем, .икәя;

б) а.әң, да.и, .әйкәл;

в) мә.әббәт, и.тирам, .алат.

4. Хәрефләргә караганда авазлар саны кубрәк булган сүзне билгелә.

а) яшьлек

б) көньяк

в) бияләй

**Нокталар урынына тиешле хәрефләрне куеп күчереп языгыз.**

Төн утырып шагыйр. шигыр. язды,
Ак  к.газ.гә тамды яш.ләре.
Тышта давыл иде; бертуктаусыз
Күк күкрәде, яшен яш.нәде. (М.Җәлил)

# ъ хәрефе



нечкә әйтелешле сүздә ябык иҗек ахырында килгән *[къ]*, *[гъ]* тартыкларының катылыгын белдерә

*игълан*

**[’]** (һәмзә) тартыгын белдерә

*Коръән*

кушма сүзләрдә ***е***, ***ю***, ***я*** хәрефләре алдыннан килгәндә, **аеру билгесе** буларак кулланыла

*кулъяулык*



# Ь хәрефе

| | |
|---|---|
| нечкә әйтелешле сүздәге **[къ]**, **[гъ]** тартыклары кергән ябык иҗекне нечкәртә | *сәнгать* |
| иҗекне нечкәртә | *яшьлек* |
| алынма сүзләрдә тартыкны йомшарта | *февраль* |
| **[’]** (һәмзә) тартыгын белдерә | *мәсьәлә* |
| кушма сүзләрдә **е**, **ю**, **я** хәрефләре алдыннан килгәндә, аеру билгесе буларак кулланыла | *төньяк* |

**Күп нокталар урынына ь, ъ хәрефләрен куеп, сүзләрне күчереп языгыз һәм аларның язылышын аңлатыгыз.**

Яш…лек, ал…бом, ал…япкыч, гар…ләнү, канәгат…, В…етнам, кор…ән, дик…кат…, гам…сез, портфел…, кул…язма, суд…я, бер…яклы, пул…с, мәг...лүм, мәс...әлә, гам..., юн...ле, пак..., шәфкат..., тугыз...еллык, мең...яфрак, шөгыл..., дәр...я, мыш...як, өч...яклы, канәгат..., п..еса, ниһаят..., иг...тибар, юп...-юеш

**Кушма сүзләр** ике сүзнең кушылып бер мәгънә белдерә башлаулары нәтиҗәсендә барлыкка килә. Кушма сүзләр **кушылып язылалар.**

Мәсәлән: ак+кош= аккош, өч+почмак= өчпочмак, бу+көн = бүген, кул+ язма = кулъязма, алма+ агач = алмагач, ак + Идел = Агыйдел

**Парлы сүзләр** антоним, синоним, аваздаш сүзләрне парлап, сүзләрне кабатлап ясала. Парлы сүзләр һәрвакыт **сызыкча аша язылалар.**

Мәсәлән: әти-әни, уен-көлке, бала-чага, биек-биек, көн-төн, аз-маз, юк-бар,рәт-рәт, барлы-юклы, зәп-зәңгәр

**Тезмә сүзләр** ике яки берничә сүздән тезелеп ясалалар. Бербөтен буларак, бер төшенчәне генә белдерәләр, бер генә сорауга җавап бирәләр. Тезмә сүзләр **аерым язылалар**.

Мәсәлән: кура җиләге – малина, бака яфрагы – подорожник, дәвам итә- продолжает, бал корты – пчела, җир җиләге – земляника.

**1.Дәреслек белән эш. 28 нче күнегү (33 нче бит)**
**2.Биремнәрне үтәргә**
**1) бирелгән сүзләрдән туры килгәннәрен сайлап алып, кушма сүзләр ясарга:**
Озын борынлы, боз вата торган, билгә бәйли торган бау, эз табучы, кояш чыгу ягы, таш күмер, кара төстәге җимеш.
**2) түбәндәге ысул белән ясалган парлы сүзләргә мисаллар язарга:**
Синоним парлы сүзләр:
Антоним парлы сүзләр:
Аваздаш парлы сүзләр:
Кабатлаулы парлы сүзләр:
**3) түбәндәге тезмә сүзләр белән җөмлә төзергә:**
мүк җиләге, күз карасы, бал корты, Кара диңгез, миләш чыпчыгы, хәбәр бирү, кәлтә елан.

**Өй эше**

ъ һәм ь хәрефләре кергән һәм кушма, парлы, тезмә сүзләрдән файдаланып , “Туган ягым табигате” темасына 8-10 җөмләдән торган инша язарга.